**ГЛАВА**
**КОЗЯКОВО-ЧЕЛНИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422668, Республика Татарстан,
Рыбно-Слободский район, Иванова ул., дом 26,
с.Козяково-Челны

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КАЗАКЛАР ЧАЛЛЫСЫ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422668,Татарстан Республикасы,
Балык Бистәсе районы, Иванов урамы,
26 нчы йорт,
Казаклар Чаллысы авылы

**Тел.: (8-4361) 32-310 , факс: (8-4361) 32-310 , эл.адрес:Kcn.Rs@tatar.ru**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

. 2024 елның 8 ноябре Казаклар Чаллысы авылы № 8

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл жирлегенең Үри Чаллысы, авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар жыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Казаклар Чаллысы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе,Татарстан Республикасы Балык Бистэсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл жирлеге Советынын 17.10.2019 ел, 14 номерлы карарынын 4.4 пункты белэн расланган Татарстан Республикасы Балык Бистэсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл жирлеге составына керуче торак пунктларда гражданнар жыенын эзерлэу һэм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә нигезендә КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең Үри Чаллысы авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар жыенын 2024 елның 21 ноябрендә 14 сәг. 00 минутка билгеләргә.
2. Гражданнар жыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү территориаль билге буенча гамәлгә ашырылуын расларга.
3. Гражданнар жыены каравына куела торган сорауны расларга:

Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең Үри Чаллысы авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, беренче торкем инвалидлардан, мобилизациялэнгэн гражданнар һэм аларнын гаилэ эгзаларыннан гайре) 1000 сум күләмендә үзара салым

акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- торак пунктлар чиклэрендэ жирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, хезмәт күрсәтү;

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау.

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Үри Чаллысы авылы, Гаврилов урамы, 24 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда.

5. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Казаклар Чаллысы авыл җирлеге башлыгы Ф.Х.Хәсәншин

СОВЕТ КОЗЯКОВО-ЧЕЛНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ